ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

**« 29 » июня 2017 ел** **№ 754**

**2017 елга Арча муниципаль районы коммуналь комплекс оешмаларының халыкка күрсәтелә торган торак-коммуналь хезмәтләргә тарифларга үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Торак кодексына 2017 елның 1 гыйнварыннан расланган үзгәрешләр нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль закон нигезендә, Арча район башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2017 елның 1 июленнән халыкка күрсәтелә торган торак-коммуналь хезмәтләргә тарифларны расларга.

2. 26.12.2016 ел, №1364 карарның 1 нче кушымтасына үзгәреш кертергә һәм яңа редакциядә бәян итәргә

3. Әлеге карарны «Татмедиа» ААҖ филиалы «Арча хәбәрләре «газетасы редакциясе газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында ()pravo.tatarstan.ru) Арча муниципаль районының рәсми сайтындаурнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы Р.В. Хәбибуллинга йөкләргә.

Җитәкче И. Ә. Галимуллин

*Башкарма комитетның*
*«___»____________ 2017ел, № ___*
*карарына 1 нче кушымта*

**2017 елга торак урынынnан файдаланган өчен түләү (наем өчен түләү), социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучылар, шулай ук күпфатирлы торак йорт белән идарә итү ысулын сайлап алу турында Карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак урынын (алга таба – халыкка торак хезмәтләре) тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләме**

| № | Түләү исеме | Түләү алына торган үлчәү берәмлеге | Хезмәт күрсәтү үлчәү берәмлеге өчен тариф (сумнарда), 2017елның I яртыеллыгында. | Хезмәт күрсәтү үлчәү берәмлеге өчен тариф (сумнарда), 2017елның II яртыеллыгында. |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Торак фонды белән идарә итү | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м | 2,06 | 2,45 |
| 2. | Торак биналарны санитар чистарту һәм санитар чистарту: ишегалды җыештыру | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м | 2,58 | 3,20 |
| 3. | Йорт эчендәге гомуми файдаланудагы урыннарны җыештыру | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м | 2,04 | 2,12 |
| 4. | Торак биналарны агымдагы ремонтлау һәм йорт яны территориясен төзекләндерү | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м | 2,61 | 3,20 |
| 5. | Дератизация | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м | 0,17 | 0,18 |
| 6. | Йорт эчендәге инженер җиһазларына техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау:<br>- йорт эчендәге санитар-техник челтәрләр;<br>- җылыту челтәрләре;<br>- электр белән тәэмин итү челтәрләре<br>-газ белән тәэмин итү челтәрләре | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м | 1,90<br>0,10<br>0,78<br>0,22 | 1,70<br>0,10<br>0,40<br>0,10 |
| 7. | Торак йортны карап тотуга салкын су | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м | - | 0,15 |
| 8. | Торак йортны карап тотуга электр белән тәэмин итү | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м | - | 0,65 |

Инфраструктура үсеше бүлеге
ТКХ, энергетика һәм элемтә буенча секторы мөдире И. А. Рәхимов